**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№ 82** **« 19» июня 2023 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» 2014 елның 20 февралендәге 106 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 6 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының авыл җирлеге Советы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлегенең 2014 елның 20 февралендәге 106 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең 19 статьясындагы 3 өлешенә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Раиса) сүзләре белән алмаштырып, үзгәреш кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **Н.Ә. Гатина**